




*1926-1991 елларда АЗАТ ХАТЫН 2020 АПРЕЛЬ №4*

# Сөембикә

## Журналына күзәтү.

# СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!



Рифат Сәлах

***Апрель***

***Апрель бүген.***
***Әнә апрель көлә,***
***Апрель балкый кара күк йөзендә.***
***Апрель ялкынында төн яна.***

***Апрель көлә***
***Бөреләргә кунып.***
***Апрель көлә карап кошларга.***
***Март аенда тынган бураннарны***
***Апрель җилләренә кушарга.***

# АКТУАЛЬ ТЕМА


Илкүләм проект | демография

«ҺӘР ЯЛНЫ ТУГАННАРЫМНЫ ЖЫЯМ»

“Ныклы гайлә кору һәм аны яшәтү зур хезмәт ул,- ди Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты гражданлык хәле акытларын теркәү идарәсе башлыгы Гөлшат НИГЪМӘТУЛЛИНА. – Ир белән хатын бер-берсенә ярашып, икесе бергә төзегән кечкенә дәүләтне сакласа, якласа гына уртак тормыш мәгънәле булачак. Ә моның өчен икең бер якка карап яшәргә кирәк”.

Чулпан Галиәхмәтова




## БЕЗ БУЛДЫРАБЫЗ “БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА

Соңгы ноктамны куярга да өлгермәдем, яңалык килеп иреште:

“Астрахань-24” телеканалына талантлы идарәче, журналистикада азу ярган, һәркем белән уртак тел таба белгән яңа җитәкче-Динара МӘҖИТОВА билгеләнде”, диелгән иде анда

Урамда таныш булмаган баланың: “Сәлам, Динара апа!”- дип, туган телдә эндәшүенә ияләштем инде.

Раилә Хәялиева.




# НИЧЕК БАР-ШУЛАЙ “ ФИКЕР

- -Сине эстраданың “ала каргасы” дип әйтәләр. Үпкәләмисеңме?
- - Юк, мин аны хәтта комплемент итеп кабул итәм. Башкаларга охшамаганлыгымны беләм, бу ягым үземә бик тә ошый. Уйнарга . Кыланырга, кемгәдер яраргa тырышырга яратмыйм. Зур компанияләр минеке түгел. Янымда аралашыр өчен берничә якын кешем бар. Шулар җитә.

- Ч. Галиәхмәтова

# ӘНКӘЙ БЕЗНЕ СӨННӘН АЛЫП КАЙТКАН...







***Фаттаховлар гайләсе- үзе бер кечкенә дәүләт кебек. Үз кануннары, тәртипләре, матур традицияләре бар аның. Уңышларга ирешү, алдынгы булу, җиңә белү серләре бар... Ачасы иде шуларны.***

***“Бер алманы бишкә бүлеп ашаган балалар алар”, - ди әнкәләре.***

Эльмира Закирова

# ХӘЗИНӘ" ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮҢЕЛ БИЗӘКЛӘРЕ


Хәзинә » халкыбызның күңел бизәкләре

САБА КӨМЕШЧЕЛӘРЕ

Татар көмешчеләренең даны кайчандыр дөньяга таралган булган. Болгар бабаларыбыздан ук башланган бу осталык (бәлки, аннан да иртәрәктер әле!) – Казан ханлыгы чорларын узып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән иң борынгы һөнәрләрнең берсе. Саба яклары – гомер-гомергә әнә шул борынгы һөнәр ияләре – зәркәнчеләр төбәге саналган. «Саба көмешчеләре ерак-еракларга барып чыгып, алка, йөзекләрен сатып йөргән», – дип сөйлиләр. Димәк, Саба осталарының ювелир эшләнмәләре әллә кайларга кадәр барып җиткән!

Борынгы һөнәр ияләре белән танышырга, эшләрен күрергә дип, шул якларга ашкынсак та, әлеге эшне белүчеләрдән Тенеки авылында бер Хәлим абый Габдрахманов кына калган булып чыкты. Югыйсә бу авылда көмешче осталарның алка-беләзекләре һәр гаиләнең диярлек кадерле ядкаре булып саклана әле. Хатын-кызларның колагында борынгы калач алкалар ялтырап киткәли, «кара алтын»лы беләзекләр, басма йөзекләр дә әллә ни ерак куелмаган

Лилия
ГӘРӘЕВА


2020 | апрель

Саба яклары – гомер-гомергә әнә шул борынгы һөнәр ияләре-зәркәнчеләр төбәге саналган. "Саба көмешчеләре ерак-еракларга барып чыгып, алка, йөзекләрен сатып йөргәннәр", - дип сөйлиләр. Димәк, саба осталарының ювелир эшләнмәләре әллә кайларга кадәр барып җиткән!

Лилия Гәрәева.

УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

# АКТАНЫШ РАЙОНЫ ИСКЕ КОРМАШ КЫЗЫ МӘСГУДӘ ЗАКИРОВАДАН ШИГЪРИ ТӘЛГӘШЛӘР.



## Әнкәй оекбашы.

Чорналып беткән уйларымны
Охшатамын әнкәй йомгагына.
Бишинәдән төшкән оекбашны
Киеп йөрдем әле яңа гына.

Җылы оекбашлар, бияләйләр
Күпме салкыннардан саклаган.
Кичләр буе йонын язып, эрләп,
Бәйлим диеп, әнкәй ятмаган.
Бик кадерләп саклыйм соңгы парын,
Сирәк кенә аны киямен.
Әнкәй кулларының җылылыгын
Мамык йоннарында тоямын.


Роза
МУЛЛАНУРОВА

«ХУШ, ЯКТЫ
ЙОЛДЫЗЫМ»

Йомшак-ягымлы, моңлы, югары лирик колоратур сопрано тавышка ия җырчы ШӘФИКА КОТДУСОВА опера театры сәхнәсендә тудырган образлар, чит ил классикларының үлемсез әсәрләрендәге героинялар халык күңеленә уелып калган икән, димәк, сәнгать дөньясында аның үз урыны булган. Йолдыз кебек нурлы, якты шәхес дип бәяләүләре юкка түгел.

Роза Мулланурова




“Сөембикә” (“Азат хатын”) журналы тарихы республика үткән юлдан аерылмый.

Журнал битләрен актарабыз...

Әйе, без төрлебез төрле чорда яшәгәнбез. Әмма кызыксынулар, мавыгулар, уй-хыяллар, теләкләр, хәтта максатлар да бер үк шикелле...


ЖЫР СОРАП ТИПКӘН ЙӨРӘК БАР...

Бирегез мәйдан!

Сәҗидә апа

*Эльмира ШӘРИФУЛЛИНАдан хатын-кызларга багышланган шигырьләр шәлкеме.*

***Моңның йөрәге-синдә!***


*Композитор Сара Садиковага*

*Туган җиргә табынгансың,*
*Давыл булып кабынгансың,*
*Кар-бураннар ябынгансың*
*Көйләреңдә, Сара апа!*

*Күңелләрдән саркыгансың,*
*Ефәк нурлар талкыгансың,*
*Йолдыз булып балкыгансың*
*Көйләреңдә, Сара апа!*

*Гөл, чәчәк булып шыткансың,*
*Утлы күмерләр йоткансың,*
*Туфан-су булып купкансың*
*Көйләреңдә, Сара апа!*

## “МАНДАРИННАР” ХИКӘЯЛӘР КИТАБЫ ЛАНДЫШ ӘБҮДӘРОВАНЫ УКУЧЫЛАРГА ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ ЯЗУЧЫ БУЛАРАК АЧТЫ. АВТОРНЫҢ БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ЕЛЛАРЫНДАГЫ АВЫЛ ТОРМЫШЫН ТАСВИРЛАГАН ХИКӘЯСЕН ТӘГЪДИМ ИТӘБЕЗ.




Тол хатын боларны кычкырып әйтеп тормады, аклану көтеп, бәбәкләрен үзенә терәгән бу икәүгә аркасын куеп басты да савыттагы сөтне өч йомрыга салып балаларына тоттырды. Элеккеге ягымлы Зәйнәп апаларының соңгы вакытта ажгырып йөрүенә ияләшкән балалар әниләре ни кушса шуны үтәргә әзер иде- йомрыларны сүзсез генә кулларына алдылар да “хәзер нишләргә?” дигәндәй, әниләренә төбәлделәр.

- Кайсының кулыннан ала аласың, Зәйнәп? Ал!- диде Миңниса тыныч кына



**ЯШӘЕШ** НИ ХӘЛЕҢ БАР, КЕШЕ ТУГАНЫМ **“БЕЗНЕҢ ПОЧТА**



Хөрмәтле укучыларыбыз!

Сездән хатлар көтеп калабыз.

Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.

email: ssuum@yandex.ru

# ИРЛӘР КҮЗЛЕГЕННӘН

*Гайлә йөген тарту хатын-кызга йөкләнмәгән. Әмма ул шушы йөккә җигелә икән, ир-ат аңа дилбегәне бик теләп тоттыра. “Хатын өстери бит әле”, -ди, һәм чын ир-ат булудан туктый.*

*Ир кеше үзен баш итеп, гайләсе өчен әһәмиятле кеше итеп тоярга тели. Ә сез, хатын-кызлар, аңа бу мөмкинлекне бирегез!*

Фикерләрне Лилия Гәрәева язып алды



ЧЫН ХАТЫН ИРДӘН РЫЦАРЬ ЯСЫЙ

Искәндәр СИРАЖИ, журналист, язучы

Фикерләрне Лилия ГӘРӘЕВА язып алды.

## БЕЗ КИЧЕРГӘН СУГЫШ “ ЯЗМЫШ




## ЯШӘЕШ

Бу язма тыл ветераны, Россиянең мәгариф отличнигы Рәхилә Нәбиулла кызы һәм ике кызыл Йолдыз ордены, күп кенә орден-медальләр белән бүләкләнгән сугыш ветераны, ветеран-укытучы Абдулла Шакир улы Буреевлар турында.

“Кабат-кабат әйтәм, артык сагынам,  
Өзелеп сагынам бергә чакларны.  
Шул вакытны искә алу өчен  
Язам сезгә сәлам хатларны...  
Абдулла.  
1941 елның 8 декабре”

Гөлназ Исмәгыйлева

# БАЛАЧАГЫБЫЗНЫ СУГЫШ УРЛАДЫ “ ХӘТЕР




Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без- балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә.

Лилия Гәрәева

# СӘЯХӘТ" МИН АЧКАН ДӨНЬЯ


МӘҢГЕЛЕК КОЯШ ИЛЕ

***ИТАЛИЯ ТУРЫНДА КҮП СӨЙЛӘП БУЛЫР ИДЕ. МИН КҮРГӘН БУ ШӘҺӘРЛӘРНЕҢ ҺӘРКАЙСЫ АЕРЫМ ЯЗМАГА ЛАЕК. АНДА- МАТУРЛЫК, МӘХӘББӘТ, АНДА- МӘҢГЕЛЕК КОЯШ!***


Алтынчы көн. Флоренция

Җиденче көн. Венеция

АЛИНӘ ГОБӘЙДУЛЛИНА




***Динар ШАКИРОВ фикерләре.***

***Дүртөйле шәһәре прокуроры,***


***Башкортста;***

***Гайлә стажы- 17 ел;***

***Өч бала атасы***

ХУЖАБИКӘ" СӘЛАМӘТЛЕК

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ




**БАЛА БАШ СӨЯГЕНӘ ТРАВМА АЛГАНДА БЕРЕНЧЕ ЯРДӘМ ХАКЫНДА РЕСПУБЛИКА БАЛАЛАР ХАСТАХӘНӘСЕНЕҢ НЕЙРОХИРУРГИЯ БҮЛЕГЕ МӨДИРЕ, ТАБИБ-НЕЙРОХИРУРГ ВЛАДИМИР ИВАНОВ.**

**АШКАЗАНЫ АСТЫ БИЗЕ ЯЛКЫНСЫНУЫ ХАКЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫНЫҢ ШТАТТАН ТЫШ ХИРУРГЫ ҺӘМ ТРАНСПЛАНТОЛОГЫ. ПРОФЕССОР АНДРЕЙ АНИСИМОВ.**



ХУЖАБИКӘ" БАКЧА


ЯЗ АШЫКТЫРА



Апрель ае- бакча сезоны ачылу чоры. Җир кардан арыну белән бакчаларда кызу эш башлана

## РЕКЛАМА

*Бит тиресен тәрбияләү серләре турында “Суфле” матурлык үзәге җитәкчесе Суфия ГАБДУЛЛИНА сөйли.*



## ХУЖАБИКӘ” АШ-СУ



# Камырсыз чизкейк

Чизкейк – бүгенге көндә иң популяр десертларның берсе. Аны чәй яки кәһвә янына куялар. Чизкейк әзерләү фуд блогерларның яраткан шөгыле. Нинди генә уйлап тапмыйлар! Ә безгә аның камырсызгына, тиз арада печеньедан әзерләнә торганын декрет ялында да мең төрле шөгыль табып яшәүче яшь әни Айгөл ТАҖИЕВА өйрәтте. Айгөл – Башкортстан кызы. Һөнәре буенча – педиатр. Сөләйман һәм Карим исемле уллары – нәни ярдәмчеләре үсеп килә. Аш бүлмәсендә бергәләп тәм-томнар пешерергә яраталар. «Кич йокларга ятар алдыннан төрле рецептлар укыйм, өйдәгеләргә һәрвакыт яңа ризык әзерләргә тырышам», – ди Айгөл. Туган көннәрдә, төрле бәйрәмнәрдә табын яме булырлык татлы ризыкны, әйдәгез, бергәләп әзерләп карыйк.

**Кирәк**

- 400 г эремчекле сыр;
- 10 г желатин;
- 200 г печенье;
- 150 г куертылган сөт (майлылыгы югарырак булган саен, тәмлерәк);
- 150 г шикәр комы;
- 70 мл су (желатинны эретер өчен);
- 80 г атланмай.

***Башкотрстан кызы Айгөл ТАҖИЕВАдан камырсыз чизкейк әзерләү серләре.***


***Чәйләрегез-чизкейклы, көннәрегез ямьле булсын, дуслар!***

# ХУЖАБИКӘ" ДӨРЕС ТУКЛАНУ




***Аборигеннар авокадоны "мәхәббәт җимеше" дип атый. Юкка түгел, авокадо – бик көчле афродизиак.***

Камилә Димөхәммәтова



# ИГЪТИБАРЫГЫЗ ӨЧЕН ЗУР РӘХМӘТ !

*ӘЗЕРЛӘДЕ ИСКЕ АЙМАН КИТАПХАНӘЧЕСЕ ХӨҖӘТОВА ГӨЛНАЗ В.*